КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

17.07.2025 №72-п

«Күпчалымлы Россия»
бөтенроссия журналистлар
конкурсын
үткәрү турында

«Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында БОЕРЫК БИРӘМ:

1. «Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсын үткәрү турында нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү турында» 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы боерыгы белән расланган «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 9 июнендәге 86-п номерлы;

«Журналистларның «Күпчалымлы Россия» гомумроссия еллык конкурсын үткәрү турында» 2022 елның 15 февралендәге 13-п номерлы;

«Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга республика журналистлар конкурсын үткәрү турында» 2022 елның 18 мартындагы 28-п номерлы;

«Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга республика журналистлар конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 18 мартындагы 28-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 23 мартындагы 54-п номерлы;

«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 июлендәге 137-п номерлы;

«Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2021 елның 21 апрелендәге 52-п номерлы боерыгы белән расланган «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 19 апрелендәге 89-п номерлы;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 18 мартындагы 28-п номерлы боерыгы белән расланган Халыклар һәм диннәр арасындагы мөнәсәбәтләрне Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында иң яхшы яктыртуга республика журналистлар конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 26 июнендәге 145-п номерлы;

«Журналистларның «Күпчалымлы Россия» гомумроссия еллык конкурсын үткәрү турында» «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 2022 елның 15 февралендәге 13-п номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 сентябрендәге 197-п номерлы;

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары И.Ф. Миргалимовка йөкләргә.

Җитәкче                                                                                   А.С. Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының
2025 елның 17 июлендәге 72-п номерлы боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**«Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсын үткәрү турында НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында «Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсын (алга таба – Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы (алга таба – Агентлык, Оештыручы); Милләтләр эшләре буенча федераль агентлык (Россия ФАДН) һәм «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясы» региональ иҗтимагый оешмасы ярдәме белән.

1.3. Конкурс ел саен 31 октябрьгә кадәр үткәрелә.

Конкурсны үткәрү турындагы мәгълүмат Агентлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://tatmedia.tatarstan.ru) «Яңалыклар», «Конкурслар һәм проектлар» бүлекләрендә (алга таба– Агентлыкның рәсми сайты) урнаштырыла. Конкурс үткәрү турындагы мәгълүматта Конкурсны үткәрү шартлары, номинацияләр, шул исәптән, өстәмә номинацияләр, конкурс эшләрен бәяләү критерийлары һәм тәртибе, гаризалар кабул итүнең урыны, сроклары, башлану һәм тәгәлләнү вакыты, аны бирү тәртибе, бүләкләү күләме һәм рәвешләре, шулай ук Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү тәртибе һәм сроклары күрсәтелә.

1.4. Конкурста җиңүчеләргә дипломнар, чәчәкләр һәм акчалата бүләкләр тапшырыла;

1.5. Конкурска билгеле бер номинациядә бер генә гариза керсә яисә бер гариза да кермәсә, бу номинациядә Конкурс үткәрелмәде дип таныла.

1.6. Әлеге Нигезләмәдә файдаланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр:

Сервис – «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасын булдыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 2 ноябрендәге 986 номерлы карары нигезендә барлыкка килгән һәм электрон исәпләү машиналары өчен программалар, белешмәләр базасы һәм интеллектуаль эшчәнлекнең башка нәтиҗәләре рәвешенә белдерелгән, халык дәүләт ярдәме чараларын электрон рәвештә алу максатларында гаризалар бирү хокукын гамәлгә ашыру өчен күздә тотылган мәгълүмат системасы. Сервис функцияләреннән файдалану, Сервистан файдалану турындагы килешү нигезендә, «Интернет» челтәрендәге сайт (http://subsidiya.tatarstan.ru, http://subsidiya.tatarstan.ru) яисә мобиль кушымта аша башкарыла;

ГЭИ – гади электрон имза;

блог – эчтәлеге күпмилләтле Россия халыкларының тормышы, мәдәнияте, традицияләре, халыкларның мәдәни үсешкә һәм мәдәни мирасны саклап калуга, халыклар һәм диннәр арасындагы татулыкны һәм дуслыкны саклауга һәм җайга салуга, гомумгражданлык бердәмлеген ныгытуга, шулай ук яшь буынны халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә ихтирам итү рухында тәрбияләүгә өлеш кертә торган этномәдәни үсеш һәм үзара эшчәнлек мәсьәләләре яктыртылучы текст, сурәт яисә мультимедиа рәвешендә даими өстәлеп торучы язмалардан гыйбарәт вакыйгалар интернет журналы, социаль челтәрләрдә аккаунт яисә төркем, мессенджерларда һәм видеохостингларда канал;

блогер – күпмилләтле Россия халыкларының тормышы, мәдәнияте, традицияләре, халыкларның мәдәни үсешкә һәм мәдәни мирасны саклап калуга, халыклар һәм диннәр арасындагы татулыкны һәм дуслыкны саклауга һәм җайга салуга, гомумгражданлык бердәмлеген ныгытуга, шулай ук яшь буынны халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә ихтирам итү рухында тәрбияләүгә өлеш кертә торган этномәдәни үсеш һәм үзара эшчәнлек мәсьәләләре яктыртыла торган үз сайтын, социаль челтәрләрдә аккаунтын яисә видеохостингларда яисә мессенджерларда каналын алып баручы интернет файдаланучы.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурсның максаты:

массакүләм мәгълүмат чараларында журналистларның күпмилләтле Россия халыкларының тормышы, мәдәнияте, традицияләре, халыкларның мәдәни үсешкә һәм мәдәни мирасны саклап калуга, халыклар һәм диннәр арасындагы татулыкны һәм дуслыкны саклауга һәм җайга салуга, гомумгражданлык бердәмлеген ныгытуга, шулай ук яшь буынны халыклар вәкилләренең мәдәниятенә, теленә, традицияләренә һәм гореф-гадәтләренә ихтирам итү рухында тәрбияләүгә өлеш керткән аеруча әһәмиятле һәм талантлы эшләрен ачыклау һәм бүләкләү;

Россия Федерациясе халыкларының традицион рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруга игътибарны җәлеп итү;

Россия Федерациясенең полиэтник киңлеге шартларында халыкларның милли мәдәниятләренең бәйрәм традицияләренең дәвамчанлыгын саклауга һәм үстерүгә өлеш кертә торган аеруча әһәмиятле һәм талантлы фотоэшләрне ачыклау.

2.2. Конкурсның төп бурычлары:

җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәтләр һәм татулык культурасын булдыру;

әхлакый-этик һәм гражданлык-патриотик хисләр, тарихи мирасны, туган якның традицияләрен һәм гореф-гадәтләрен сәнгати-эстетик кабул итүне тәрбияләү;

массакүләм мәгълүмат чараларында күпмилләтле җәмгыятьтә мәдәниятләр, традицияләр һәм гореф-гадәтләр төрлелеген, мәдәниара һәм динара мөнәсәбәтләрнең һәм хезмәттәшлекнең уңай мисалларын яктыртуны кызыксындыру.

2.3. Конкурсны оештыру һәм үткәрү эше түбәндәге принципларга таяна:

гавамилык һәм ачыклык;

Конкурста катнашуга гариза бирүчеләрнең тигез хокуклы булуы;

гаризаларны конкурс нигезендә карау.

## 3. Конкурсның номинацияләре

3.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

«Телесюжетлар циклы»;

«Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)»;

«Радиотапшырулар (репортажлар) циклы»;

«Басма мәгълүмат чараларында язмалар циклы»;

«Интернет массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар циклы»;

«Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-яшүсмерләр өчен проектлар»;

«Цифрлы медиада мәдәниятара бәйләнешләргә багышланган иң яхшы проект»;

«Россия Федерациясе халыкларының традицион рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен иң яхшы яктырту»;

«Фотоэшләр сериясе: Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»;

«Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне иң яхшы яктырту».

3.2. Төп приз – «Гран-при» барлык номинацияләр арасында иң күп баллны җыйган катнашучыга бирелә.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлгән редакцияләре (алга таба – ММЧ редакцияләре), авторлар, блогерлар, авторлар коллективлары катнаша.

4.2. Конкурска гариза бирүчеләр – әлеге Нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә документлар тапшырган ММЧ редакцияләре, авторлар, блогерлар, авторлар коллективлары (алга таба – гариза бирүчеләр).

4.3. Конкурста катнашучылар – тапшырылган эшләре Конкурста катнашырга рөхсәт ителгән гариза бирүчеләр (алга таба – катнашучылар).

4.4. Гариза бирүчеләр Конкурста катнашу өчен әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә бәян ителгән тәртиптә һәм күрсәтелгән шартларны, таләпләрне үтәп гариза тапшырырга тиеш.

4.5. Конкурска җибәрелгән Конкурс эшләре бер яки аннан күбрәк ММЧ редакцияләре, авторлар, блогерлар, авторлар коллективлары тарафыннан башкарылган булырга мөмкин.

4.6. Гариза бирүче Конкурсның бер номинациясендә катнашу өчен бер генә гариза бирә ала.

4.7. Конкурска гариза бирүче берничә номинация буенча документлар тапшыра ала, бу очракта жюри тарафыннан карала торган документлар һәрбер номинация буенча әлеге нигезләмәнең 5.2 пункты нигезендә аерым әзерләнергә тиеш. Бер конкурс эше төрле номинацияләргә тапшырыла алмый.

## 5. Конкурсны үткәрү шартлары

5.1. Конкурска массакүләм мәгълүмат чараларында алдагы Конкурска йомгак ясалган датадан алып чираттагы Конкурска гаризалар кабул итү тәмамлана торган датага кадәр булган чорда чыккан эшләр кабул ителә;

5.2. Конкурска түбәндәге документлар теркәлгән гариза кабул итә:

а) конкурс эшләре (иң күбе 10):

анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә телевизион эшләр (программалар, махсус репортажлар, видеосюжетлар циклы, документаль фильм). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

басма массакүләм мәгълүмат чараларындагы язмалар (язмалар сериясе, махсус чыгарылышлар), төп нөсхә яки күчермә нөсхә рәвешендә һәм (яисә) сканер аша чыгарылган вариантта тапшырыла. Язмалар массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

адреслы сылтама күрсәтелеп, интернет басмалардагы язмалар;

анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә радиоэшләр (программалар, махсус репортажлар, радиосюжетлар циклы). Конкурс эшләренә эшнең исеме, авторлары һәм эфирга чыгу датасы күрсәтелгән эфир белешмәсе кушып бирелә. Әлеге белешмә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш;

мәдәниара һәм динара багланышларны үстерүгә һәм хезмәттәшлеккә юнәлдерелгән блогларның анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама;

анкета-гаризада күрсәтелгән саклау ресурсына сылтама рәвешендә фоторәсемнәр;

б) катнашу өчен анкета (1 нче кушымта);

в) юридик зат буларак теркәлгән массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

юридик затны салым органында исәпкә кую турында таныклык (ИНН) (күчермәсе);

ММЧ теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

г) юридик зат булмаган массакүләм мәгълүмат чарасы редакцияләре өчен:

массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык (күчермәсе) йә теркәлгән массакүләм мәгълүмат чаралары реестрыннан өземтә;

д) уртак эшләрне тәкъдим итә торган ММЧ редакцияләре өчен:

шәхесне таныклаучы документ;

персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (2 нче кушымта нигезендә);

персональных белешмәләр субъект таратуга рөхсәт бирә торган персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык (3 нче кушымта нигезендә);

е) уртак эшләрне тәкъдим итә торган авторлар, авторлар коллективлары, блогерлар, МЧ редакцияләре, өчен:

конкурс эшенә призлы урын бирелгән очракта акчаны процентлап бүлешү турында килешү.

Әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән эфир белешмәләре һәм басма ММЧ язмалар, әлеге пунктның «б» - «е» пунктчаларында күрсәтелгән документлар, кәгазь документларның электрон рәвешләре буларак, ачык форматта, гамәлдәге программалар белән тәэмин ителгән җайланмалар аша тулысынча яки аерым өлешләрен карау мөмкинлеге булган килеш konkurs_zozh@mail.ru электрон почта адресына җибәрелә. Бу абзацта күрсәтелгән документлар шифр ярдәмендә яисә эчтәлек белән танышу өчен лицензияле яки башка килешү төзеп, сатып алына торган өстәмә программалар таләп ителә торган башка чаралар ярдәмендә сакланган булырга тиеш түгел. Белешмәләр өчен телефон: 8 (843) 570-31-12.

5.3. Конкурс эшләре Россия Федерациясе дәүләт телендә, Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендәге башка халыклар телләрендә тапшырыла. Россия Федерациясе составындагы республикаларның дәүләт телләрендә, Россия Федерациясендәге башка халыклар телләрендә тапшырылган эшләрнең русчага тәрҗемәсе бирелә. Ул массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы һәм мөһере (булган очракта) белән таныкланган булырга тиеш.

5.4. Конкурска килгән эшләргә рецензия бирелми.

5.5. Гариза Сервистан файдаланып йә электрон почта аша тапшырыла.

Документлар электрон рәвештә тапшырылган очракта, гариза Сервиста языла, гаризага теркәлә торган документлар, сканер аша чыгарылып, Сервиска кертелә.

5.6. Гариза, Сервистан файдаланып, электрон рәвештә бирелгәндә, гариза бирүче тарафыннан гади электрон имза (ГЭИ) белән имзаланырга тиеш.

ГЭИ ачкычы ике элементтан гыйбарәт – индентификатордан һәм парольдән. Индентификатор – гариза бирүченең ЕСИА системасындагы логины, пароль – ЕСИА пароле. Гариза бирүче физик зат булса, ул ЕСИА системасында физик зат буларак, юридик зат булса, ЕСИА системасында юридик зат буларак теркәлгән биттән файдаланырга тиеш.

5.7. Гариза бирүче тарафыннан ГЭИ формалаштыру факты түбәндәге шартларның барысын да үтәү юлы белән раслана:

Сервисның интерактив рәвешенә ЕСИА системасындагы дөрес логин һәм пароль белән керү;

норматив хокукый актлар нигезендә ЕСИАга теркәлү;

гариза бирүче – физик зат шәхесенең норматив хокукый актлар нигезендә таныклануы;

гариза бирүче – юридик затның ЕСИА системасында электрон имзаны тикшерүнең квалификацияле сертификатыннан файдаланып теркәлүе;

гариза бирүченең ЕСИА логины һәм пароле белән Сервиста теркәлүе турында Сервиска ЕСИА системасыннан мәгълүмат алыну;

Сервиска ЕСИАда теркәлгән зат турында мәгълүмат алыну.

5.8. Гариза бирүченең гади электрон имзасын тикшерү дөрес кулланылган логин һәм пароль турында Сервис тарафыннан ЕСИАдан мәгълүмат алу юлы белән башкарыла. Логин һәм пароль дөрес булса, гади электрон имза расланган дип санала.

5.9. Әлеге Нигезләмәнең 5.7 пункты таләпләрен үтәп, Сервис интерфейсында электрон документны җибәрү буенча тиешле кнопкага басу гариза гади электрон имза белән имзаланганны аңлата.

5.10. Әлеге Нигезләмәнең 5.8 пункты таләпләрен үтәп, Сервис интерфейсында электрон документны җибәрү буенча тиешле кнопкага басу юлы белән салынган гади электрон имза куелган гариза кәгазь вариантта имза куеп тапшырылган документ белән бер үк хокукка ия.

5.11. ГЭИ ачкычын куллану кагыйдәләре Сервистан файдалану турындагы килешүдә Сервис операторы тарафыннан билгеләнә.

5.12. Сервистан файдаланып формалаштырылган һәм (яисә) җибәрелгән электрон документта электрон документны формалаштырган һәм (яисә) җибәргән гариза бирүчегә кагылышлы мәгълүмат була.

5.13. Гариза бирүче ГЭИ ачкычының конфиденциаль булуын таный.

5.14. Сервис аша гариза тапшырылган көн яисә гризаның Агентлыкка кергән көне Конкурста катнашу өчен гариза тапшыру датасы булып исәпләнә.

5.15. Конкурста катнашуга рөхсәт бирмәү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

гаризаның әлеге Нигезләмәнең 5.1. – 5.3. пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яисә гаризага әлеге Нигезләмәнең 5.2. пунктында каралган документларны теркәмәү (барысын да теркәмәү);

конкурста катнашу өчен гаризаны билгеләнгән срокны бозып тапшыру;

сурәтендә яисә тавышында хилафлыклар булган эшләр тәкъдим итү;

гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 4.1, 4.2 пунктларында каралган таләпләргә туры килмәве.

гариза бирүче 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусына ия булу (авторлар коллективы әгъзасы (лары) «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия булган очракта, чит ил агенты (лары) дип танылган заттан кала, авторлар коллективына рөхсәт ителә);

тапшырылган конкурс эшенең конкурс һәм (яисә) номинация темасына туры килмәве.

5.16. Конкурска кертелмәгән эшләр, җитешсезлекләре бетерелеп, документлар тапшыру өчен билгеләнгән срокларда яңадан Конкурска тәкъдим ителергә мөмкин.

5.17. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү датасы турында Агентлыкның рәсми сайтында өстәмә рәвештә хәбәр ителә.

5.18. Конкурсны оештыручы эшләрне, шул исәптән бүләкләргә лаек булган эшләрне дә киләчәктә файдалануны күздә тотмый, шуңа бәйле рәвештә, конкурста катнашучылар эшләрне киләчәктә ничек файдалануны мөстәкыйль хәл итә.

5.19. Катнашучыга Конкурска кертелмәү турында хәбәр документларны алган көннән алып биш эш көне эчендә, Оештыручы җитәкчесе (җитәкче урынбасары) имзалаган һәм анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы хат белән хәбәр ителә.

5.20. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) гариза тапшыручы һәм катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

5.21. Өченче затларның авторлык хокукларын үтәмәгән өчен җаваплылык, законнар нигезендә, эшләрне тәкъдим иткән гариза бирүчеләргә һәм катнашучыларга йөкләнә.

## 6. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары

6.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

материалның темага туры килүе (0-5 балл);

эчтәлекнең Конкурс тематикасын чагылдыруы (0-5 балл);

башкару осталыгы (0-5 балл);

эшләрнең иҗади булуы (0-5 балл);

тематиканы яктыртуның кабатланмаган һәм тапталмаган булуы (0-5 балл).

## 7. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

7.1. Конкурс комиссиясе Оештыручы боерыгы белән 14 кеше составында раслана һәм рәистән, рәис урынбасарыннан һәм комиссия әгъзаларыннан төзелә.

7.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

7.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип таныла.

7.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

7.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәйләнә.

Баллар суммасы буенча конкурс комиссиясе һәр номинация буенча катнашучыларның рейтингын төзи. Рейтинга нигезендә конкурс комиссиясе һәрбер номинациядә җиңүчеләр исемлеген төзи.

1 дән артык конкурс эше теркәлгән гариза буенча баллар саны, гариза составындагы конкурс эшләренең һәрберсе буенча конкурс комиссиясе әгъзаларының бәясеннән чыгып, уртача баллны исәпләү юлы белән санала.

7.6. Конкурска гариза бирүче эшен тапшырганда Конкурс номинациясен дөрес билгели алмаган очракта, Конкурс комиссиясе Конкурс эшенә туры килә торган номинацияне мөстәкыйль билгели.

Бер номинациягә бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс бу номинациядә үткәрелмәгән дип таныла һәм акчалар Оештыручы тарафыннан башка җиңүчеләр арасында тигез итеп бүленә.

7.7. Баллар тигез булганда Конкурс комиссиясе әгъзалары карары нигезендә призлы урыннар ике яисә берничә җиңүчегә бирелергә мөмкин, бу очракта әлеге призлы урынга тәгаенләнгән акчалар җиңүчеләр арасында Оештыручы тарафыннан тигез өлешләп бүленә һәм җиңүчеләрнең һәрберсенә бер призлы урын бирелә.

7.8. Җиңгән эш берничә ММЧ тарафыннан тапшырылган булса, бу призлы урын өчен тәгаенләнгән акча ул эшне башкаруда катнашкан затлар арасында үзләре килешенгән күләмдә бүленә. Мондый килешү конкурс комиссиясенә тапшырылган гариза белән бергә бирелә.

7.9.Иң күп баллны бертигез дәрәҗәдә җыйган катнашучылар булганда, «Гран-при» иясе тавыш бирү юлы белән ачыклана. Тавышлар саны тигез булганда, Рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

7.10. Конкурсны оештыручы оештыру-техник эшчәнлекне җайга салу, утырышны әзерләү һәм конкурс комиссиясе документациясен алып бару өчен җаваплы секретарь билгеләп куя.

7.11. Җаваплы секретарь конкурс комиссиясе составына керми һәм утырышларда тавыш бирү хокукыннан башка гына катнаша.

7.12. Конкурска йомгак гаризалар кабул итү тәмамланган көннән алып 30 календарь көн эчендә ясала, Конкурс комиссиясе утырышы йомгаклары буенча беркетмә рәсмиләштерелә, аңа утырышта булган конкурс комиссиясе әгъзаларының имзасы салына, беркетмә, конкурска йомгак ясалган көннән алып биш көн эчендә, конкурс комиссиясе рәисе яисә рәисе урынбасары тарафыннан раслана.

7.13. Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе кул куелган көннән алып өч календарь көн эчендә Агентлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

## 8. Финанс белән тәэмин итү

8.1. «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 18 декабрендәге 1006 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында киләсе финанс елына Конкурс үткәрү өчен Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

8.2. Конкурста җиңүчеләр түбәндәге тәртиптә бүләкләнә:

**«Гран-при»** - 500,0 мең сум (Диплом).

**«Телесюжетлар циклы»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Телепроект (документаль фильм, телепрограммалар циклы)»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Радиотапшырулар (репортажлар) циклы)»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Басма мәгълүмат чараларында язмалар циклы»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Интернет массакүләм мәгълүмат чараларында материаллар циклы»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).

2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Массакүләм мәгълүмат чараларында балалар-яшүсмерләр өчен проектлар»**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Цифрлы медиада мәдәниятара багланышларга багышланган иң яхшы проект»;**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Россия Федерациясе халыкларының традицион рухи-әхлакый һәм гаилә кыйммәтләрен иң яхшы яктырту»;**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Фотоэшләр сериясе: Россия халыкларының милли бәйрәмнәре»;**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

**«Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чараларында этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне иң яхшы яктырту».**
1 урын - 100 000 сум. (I дәрәҗә диплом).
2 урын - 80 000 сум. (II дәрәҗә диплом).
3 урын - 50 000 сум. (III дәрәҗә диплом).

8.3. Юридик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, анкета-гаризада күрсәтелгән кредит оешмасындагы исәп-хисап счетына күчерү юлы белән түләнә.

8.4. Физик затларга акчалата премияләр Конкурс йомгаклары турында беркетмәгә имза салган мизгелдән алып 20 көн дәвамында, җиңүчеләрне игълан иткәннән соң, анкета-гаризада күрсәтелгән кредит оешмасындагы исәп-хисап счетына күчерү юлы белән яисә Агентлыкның финанс бүлегендә (салымны исәпләп) түләнә.

## 9. Аерым шартлар

9.1. Оештыручылар түбәндәгеләргә хокуклы:

- әлеге Нигезләмәдә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында билгеләнгән очраклардан, шулай ук бәхәсле очраклардан тыш, Конкурста катнашучылар белән язмача йә башка төрле элемтәләргә кермәскә;
- эшләрне тапшыру срогының беренче яртысында Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп, Конкурсны туктатырга яки әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә, бу хакта Агентлыкның рәсми сайтында тиешле мәгълүмат урнаштырып, Катнашучыларга хәбәр итәргә.

9.2. Конкурс шартлары үзгәрү турында хәбәрнамә алганнан соң, Конкурста катнашучы эшләрне элек билгеләнгән шартларда кабул итүне яисә кертелгән үзгәрешләрне гамәлдә түгел дип тануны таләп итә алмый. Аның эшне Конкурсның яңа шартларына туры китереп үзгәртүе алга таба конкурста катнашырга мөмкинлек бирә.

9.3. «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

Бәйгедә катнашучы авторлар коллективы составында конкурска кертелгәннән соң «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә чит ил агенты дип танылган катнашучы булса, мондый авторлар коллективы чәчәкләр, диплом һәм акчалата премия белән бүләкләнми.

«Күпчалымлы Россия»
бөтенроссия журналистлар
конкурсын үткәрү турында
нигезләмәгә
1 нче кушымта
(тәкъдим итела торган форма)

Конкурста катнашу өчен анкета-гариза

Гариза бирүче (ММЧ; авторның, авторлар коллективының Ф.И.Ат. ис.*)

Номинация исеме

Конкурска тәкъдим ителгән эшнең исеме

Аннотация

Конкурс эше урнаштырылган саклау ресурсы

Адрес

Телефон

Электрон почта

Гариза бирүченең банк реквизитлары (банк исеме, ИНН һәм КПП, БИК, исәп-хисап счеты номеры
ИНН (физик затлар өчен)
СНИЛС (физик затлар өчен)

Түбәндәгеләрне раслыйм:

«Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсына тәкъдим ителгән конкурс материалларында өченче затларның авторлык һәм башка хокукларын боза торган материаллар юк;

«Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты статусым юк;

авторлар коллективы составында «Чит ил йогынтысындагы затларның эшчәнлеген тикшереп тору турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил статусына ия затлар юк**.

* Атасының исеме булган очракта күрсәтелә
** Гариза авторлар коллективы тарафыннан бирелгән очракта күрсәтелә

Дата ________________

Имза ____________________ ___________________________
(фамилия)

«Күпчалымлы Россия»
бөтенроссия журналистлар
конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык

Мин,_____________________________________________________________,
яшәү адресым_____________________________________________
_____________________________________________________________________________,
шәхесне таныклаучы төп документым (паспорт)______________________
_____________________________________________________________________________
____________________________________, “Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (алга таба – оператор) (адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) «Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне эшкәртүгә, аларны җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), алардан файдалануны, аларны таратуны (шул исәптән башкаларга тапшыруны), үз исемемнән башка файдалануны, блокировать итүне, юкка чыгаруны да кертеп, ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалыгымны бирә торган персональ белешмәләрнең исемлеге:

(фамилия, исем, атасы исеме, җенес, туган көн һәм урын, гражданлык, шәхесне таныклаучы документның реквизитлары (документ төре, сериясе һәм номеры, кем тарафыннан бирелүе), яшәү урыны, теркәлү урыны, телефон номеры (шул исәптән кәрәзле телефон), электрон почта адресы, Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счеты турында белешмәләр), ИНН, СНИЛС

Әлеге ризалык имзаланган көннән алып 1 (бер) ел гамәлдә була.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны, бу хакта операторга язмача хәбәр итеп, кире алырга хокуклы.

Персональ белешмәләрнең субъекты үз персональ белешмәләрен эшкәртүгә әлеге ризалыкны кире алган очракта оператор аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм, персональ белешмәләрне эшкәртү өчен аларны саклау башкача кирәк булмаса, ризалыкны кире алу турында мөрәҗәгать кергән көннән алып утыз көн эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) тиеш. Күрсәтелгән вакыт эчендә персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор аларны блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (персональ белешмәләрне эшкәртү оператор йөкләмәсе буенча башка затка тапшырылган булса) һәм персональ белешмәләрне иң күп дигәндә алты ай эчендә юкка чыгара.

______________________________________________/__________
персональ белешмәләр субъектының Ф.И.Ат ис. (булган очракта күрсәтелә) һәм имзасы

Дата _________________.

«Күпчалымлы Россия»
бөтенроссия журналистлар
конкурсын үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта
(тәкъдим ителә торган форма)

Тарату өчен персональ белешмәләр субъекты тарафыннан рөхсәт ителгән персональ белешмәләрне эшкәртүгә ризалык

Мин,____________________________________________________________,
(фамилия, исем, атасының исеме (булган очракта)

_______________________________________________________________,
(почта адресы)

_______________________________________________________________,
(электрон почта адресы)

_______________________________________________________________,
(телефон номеры)

“Персональ белешмәләр турында” 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 101 статьясы нигезендә “Татмедиа” республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына (ОГРН 1031621014765, ОКТМО 92701000, ОКПО 14912163) юридик адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 йорт) «Күпчалымлы Россия» бөтенроссия журналистлар конкурсында катнашуга бәйле рәвештә үземнең персональ белешмәләрне таратуга (шул исәптән башкаларга тапшыруга, бирүгә) ризалыгымны бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

N
т/с Персональ белешмәләр Ризалык
Әйе ЮК
Гомуми персональ белешмәләр
Фамилия

Исем
Атасы исеме (булган очракта)
Җенесе
Туган ел, ай, дата һәм урын
Шәхесне таныклаучы документ (төре, сериясе, номеры, кем тарафыннан кайчан бирелгән)
Яшәү һәм теркәлү урыны
Телефон номеры
Электрон почта адресы
Россия Федерациясе кредит оешмасында ачылган счет
ИНН
Һөнәр
СНИЛС

Эшкәртү өчен шартлар һәм тыю билгеләнә торган персональ белешмәләрнең категориясе һәм исемлеге

| N т/с | Персональ белешмәләр | Билгеләнә торган шартлар һәм тыюлар исемлеге |
| --- | --- | --- |
| 1. | [Персональ белешмәләрнең категориясе] | |
| | [Персональ белешмәләрнең исемлеге] | |

Искәрмә. Күрсәтелгән таблица персональ белешмәләр субъектының теләге буенча, персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан чикләүләрсез тутырыла. Шартлар һәм тыюлар операторның чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына әлеге персональ белешмәләрне таратуга һәм (яисә) тапшыруга бәйле гамәлләрен чикләүне йә тыюны күздә тота. Ризалыкта өстәмә шартлар да күрсәтелергә мөмкин, алар алынган персональ белешмәләрне эшкәртүне гамәлгә ашыра торган оператор тарафыннан мәгълүмат кайбер хезмәткәрләргә генә җиткерелә торган эчке элемтәләр буенча йә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша тапшыруны, яки алынган персональ белешмәләрне тапшырмауны күздә тота

Операторның персональ белешмәләр субъектының персональ белешмәләре чикләнмәгән яисә кайбер даирә затларына тапшырылырга мөмкин мәгълүмат ресурслары турында белешмәләр: http://tatmedia.tatarstan.ru/.

Әлеге ризалык ____________________________ срокта гамәлдә була.
(ризалыкның гамәлдә булу срогы)

Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тартырга хокуклы.
Персональ белешмәләр субъекты, операторга язмача хәбәр итеп, үзенең персональ белешмәләрен эшкәртүгә бирелгән ризалыктан баш тарткан очракта оператор мондый баш тартуны алган көннән алып иң күбе утыз көн эчендә аларны эшкәртүне туктатырга яисә туктатуны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм, элек куелган максатлар өчен

персональ белешмәләрне эшкәртү башкача таләп ителмәсә, персональ белешмәләрне юкка чыгарырга яисә юкка чыгаруны тәэмин итәргә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) тиеш.
Күрсәтелгән срокта персональ белешмәләрне юкка чыгару мөмкинлеге булмаган очракта, оператор мондый персональ белешмәләрне блокировать итә яисә блокировать итүне тәэмин итә (әгәр бу эш оператор кушуы буенча башка зат тарафыннан башкарылса) һәм персональ белешмәләрне алты айдан артмаган срокта юкка чыгаруны тәэмин итә.

_______________(персональ белешмәләр субъекты имзасы)
_______________ (число, ай, ел)»

Җитәкче А.С. Сәлимгәрәев